КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 декабрь г.Казань № 1176

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән балаларның ялы һәм аларны савыктыру дәүләт һәм муниципаль оешмаларында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче инвалид балалар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен квоталарны үтәүне тәэмин итү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 121 статьясындагы 2 пункты нигезендә, инвалид балаларның һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларның ялына һәм аларны савыктыруга тигез мөмкинлекләр тудыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Кararга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән балаларның ялы һәм аларны савыктыру дәүләт һәм муниципаль оешмаларында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче инвалид балалар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен квоталарны үтәүне тәэмин итү тәртибен расларга.
2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 20 декабрь, 1176 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән балаларның ялы һәм аларны савыктыру дәүләт һәм муниципаль оешмаларында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче инвалид балалар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен квоталарны үтәүне тәэмин итү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән, балалар ялы һәм аларны савыктыру оешмалары реестрында алар турында белешмәләр булган балаларның ялы һәм аларны савыктыру дәүләт һәм муниципаль оешмаларында Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче инвалид балалар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен квоталарны үтәүне тәэмин итү кагыйдәләрен билгели.

2. Әлеге Тәртип максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыручылар - Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары;

оешмалар - Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән, балалар ялы һәм аларны савыктыру оешмалары реестрында алар турында белешмәләр булган балаларның ялы һәм аларны савыктыру дәүләт һәм муниципаль оешмалары;

СМЧ балалар - Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Сәламәтләнү һәм оешкан ял чорында балигъ булмаганнарга медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2018 елның 13 июнендәге 327н номерлы боерыгы белән расланган Сәламәтләндерү һәм оешкан ял чорында балигъ булмаганнарга медицина ярдәме күрсәтү тәртибенең 2 пунктында күрсәтелгән медицина ягыннан каршылыклары булмаган инвалид балалар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар;

квота - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен билгеләнә торган оешмаларда балаларның ялы һәм сәламәтләндерүе өчен урыннарының гомуми санында СМЧ балалар өчен урыннар өлеше;

квоталанган урыннар - СМЧ балаларның ялы һәм аларны савыктыру өчен билгеләнгән квота нигезендә оешмалар төзегән яисә бүлеп биргән урыннар.

Әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законда кулланыла торган мәгънәләрендә кулланыла.

3. Балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыручылар ел саен:

тиешле елга билгеләнгән квотадан һәм оешмаларда балаларның ялы һәм аларны савыктыру өчен тиешле елда планлаштырылган урыннарның гомуми саныннан чыгып, ял итү һәм сәламәтләндерүгә кабул ителә торган СМЧ балалар өчен квоталанган урыннар санын исәплиләр;

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан раслана һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла торган Балалар ялы һәм аларны сәламәтләрндерү оешмаларында СМЧ балалар өчен инклюзив сменалар уздыру буенча методик тәкъдимнәр нигезендә авырулар нозологияләре буенча СМЧ балалар ялы һәм аларны савыктыру өчен урыннар булдыралар яки бүлеп бирәләр;

ел саен 1 февральгә кадәр Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына (алга таба - вәкаләтле орган) алар билгеләгән форма буенча СМЧ балалар өчен квоталы урыннар саны турында мәгълүмат тапшыралар һәм әлеге мәгълүматны оешмаларга җиткерәләр.

4. СМЧ балалар өчен ял итү һәм сәламәтләндерү урыннары, әгәр балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыручылар тарафыннан вәкаләтле органга СМЧ балалар өчен квоталы урыннар саны турында мәгълүмат бирелгән булса, төзелгән яисә бүленгән дип санала.

5. СМЧ балалар өчен балаларның ялы оешмаларына юлламалар бирү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру турында" 2020 ел, 29 апрель, 346 нчы карары белән билгеләнгән юлламалар төре һәм аларны бирү тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. СМЧ балалар өчен квоталанган урыннарны исәпләгәндә вакланмалы санны түгәрәкләү вакланмалы күрсәткечләрне тулы күрсәткечләргә математик түгәрәкләү кагыйдәләре нигезендә билгеләнә.

7. Оешманың квотасын үтәүне тәэмин итү максатларында һәр смена башланырга 60 эш көне кала балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыручыга СМЧ балаларның ялы һәм аларны сәламәтләндерү өчен буш урыннар турында почта аша җибәрү юлы белән мәгълүмат тапшыра йә мондый мәгълүматны оешманың вәкаләтле вәкиле аша тапшыра. Балалар ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыручы һәр смена башланырга 45 эш көненнән дә соңга калмыйча күрсәтелгән мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыручының рәсми порталында урнаштыра.

Оешмалар балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыручыларга балаларның ялы һәм аларны сәламәтләндерү өчен билгеләнгән квота чикләрендә оешмаларда ирекле урыннарга СМЧ балалар сменаларын комплектлауны тәэмин итү өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

8. Оешмалар балаларның ялын оештыруга һәм тиешле календарь елга билгеләнгән квота чикләрендә СМЧ балаларның ялын оештыруга һәм аларны савыктыруга юнәлдерелгән ата-аналар яисә балаларның законлы вәкилләре белән шартнамәләр төзегән булса, квота үтәлгән дип санала.

Балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру квотасының үтәлешен раслау өчен агымдагы елда һәр сменадан соң, ул тәмамланган көннән алып 20 эш көне дәвамында балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыручыга билгеләнгән тәртиптә СМЧ балалар исемлеген, кушымта белән, баланың статусын раслаучы документның күчермәсен почта аша җибәреп яисә мондый мәгълүматны оешманың вәкаләтле вәкиле аша тапшыралар.

9. Балалар ялын һәм аларны савыктыруны оешмасында СМЧ балалар өчен юлламалар бирүгә заявкалар булмаган очракта, смена башланырга 30 календарь көн кала СМЧ балалар өчен квоталы урыннар балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыручылар тарафыннан башка категория балаларга бирелергә мөмкин.